КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 апрель г.Казань № 345

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында» 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карары белән расланган Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алуга дәгъва белдерүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында» 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карары белән расланган Авыл торак пунктларына, яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алуга дәгъва белдерүчеләрне конкурс сайлап алуы турында нигезләмәнең 4.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«4.7. Конкурс сайлап алуын үткәрү вакыты:

төбәк операторы тарафыннан гаризалар кабул итү һәм теркәү – 10 гыйнвардан 30 июньгә кадәр (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

конкурс комиссиясе тарафыннан гаризаларны һәм документларны эксперт бәяләвен үткәрү – 1 июльдән 3 июльгә кадәр (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алу буенча җиңүчеләрне билгеләү – 6 июльдән 8 июльгә кадәр (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

вәкаләтле органның һәм төбәк операторының рәсми сайтларында конкурс нәтиҗәләре буенча дәгъва белдерүчеләр рейтингын урнаштыру – 8 июльдән 9 июльгә кадәр (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

конкурс сайлап алуында җиңүчеләрнең сайлап алынган гомуми белем бирү оешмасына аның администрациясе һәм педагогик коллективы белән танышу максаты белән баруы (күчү һәм эшкә урнаштыру (гомуми белем бирү оешмасы урынына кадәр бару һәм кире кайту) белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү) – 10 июльдән 20 июльгә (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

вәкаләтле органның конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр исемлеген раслау турында боерыгын бастырып чыгару һәм вәкаләтле орган сайтында урнаштыру – 25 июльгә кадәр (ел саен чараны гамәлгә ашыру чорында);

вәкаләтле органның конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр исемлеген раслау турында боерыгын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле орган һәм төбәк операторының рәсми сайтларында урнаштыру – 31 июльгә кадәр (чараны гамәлгә ашыру чорында ел саен).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин